Икенче юнәлеш - предприятие, оешма хезмәткәрләре һәм авыл яшьләре белән массакүләм физик культура эшен оештыру.

Предприятиеләрдә физкультура кадрлары белән тәэмин ителешкә килгәндә, «ТАТЭНЕРГО» АҖнең Зәй ГРЭСы филиалында (алга таба - Зәй ГРЭСы) 1 инструктор бар. Физкультура эшен оештыру белән барлык башка предприятиеләрдә үз бурычларыннан азат ителмәгән хезмәткәрләр шөгыльләнә.

Зәй ГРЭСында персоналны савыктыру, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау һәм бу нигездә хезмәткәрләрнең нәтиҗәле хезмәт һәм башка эшчәнлек төрләренә әзерлеген тәэмин итү мәсьәләләренә зур игътибар бирелә. Спорт-сәламәтләндерү эше расланган календарь план нигезендә алып барыла. Профсоюз комитеты каршында спорт-сәламәтләндерү эше буенча комиссия төзелгән һәм эшли, ә структур бүлекчәләрдә җаваплы затлар билгеләнгән. Аларның төп бурычы персоналны физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә максималь дәрәҗәдә җәлеп итү. Әлеге максатларда станциядә ел саен 9 спорт төре буенча Спартакиада уздырыла: болар - шахмат, чаңгыда узышу, өстәл теннисы, кросс, мини-футбол, пневматик винтовкадан ату, волейбол, йөзү.

Эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең яшәү урыны буенча физкультура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен гомуми белем бирү мәктәпләренең спорт корылмалары файдаланыла. Кайбер учреждениеләр һәм оешмалар спорт корылмаларын арендага ала.

Предприятие һәм оешмалар коллективлары командалары Җиңү көненә, Шәһәр көненә, Татарстан Республикасы көненә, Физкультурачылар көненә, Бөтенроссия «Татарстан кроссы», «Россия чаңгы юллары» акцияләрендә катнаша.

Муниципаль хезмәткәрләрнең физик яктан камилләшүе өчен шартлар тудыру, Татарстан Республикасы территориясендә физкультура-спорт хәрәкәтен саклау һәм үстерү максатларында, ел саен Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләре спартакиадасы үткәрелә. Анда безнең район муниципаль хезмәткәрләренең җыелма командасы да актив катнаша.

Зәй муниципаль районы составына 22 авыл җирлеге керә, аларның территорияләрендә 79 спорт корылмасы, шул исәптән 6 футбол кыры, 7 хоккей тартмасы, гомумбелем бирү мәктәпләрендә 19 спорт залы, 9 универсаль спорт мәйданчыгы бар.

Өлкәннәр арасында халыкның хәрәкәт активлыгын арттыру, физик культура һәм спортны популярлаштыру, ял итүнең төп формалары буларак, шулай ук иң көчле спортчыларны һәм командаларны ачыклау максатыннан, 2016 елдан башлап авыл җирлекләре арасында «Сәламәтлек» спартакиадасы киңәйтелгән форматта уздырыла.

Спартакиаданы үткәрүнең төп бурычлары - авыл халкын физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү һәм Татарстан Республикасы авыл районнары арасында «Сәламәтлек» спартакиадасында

һәм «Авыл яшьләре» җәйге авыл спорт уеннары финалында катнашу өчен Зәй районы командасын формалаштыру.

Өченче юнәлеш - өлкән буын вәкилләре белән физкультура-массакүләм эш һәм сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикле гражданнар белән ярышлар оештыру.

Адаптив спорт өлкәсендә эш “Шатлык” халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексны үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе базасында алып барыла. Спорт учреждениеләре: бассейн, боз сарае, тренажерлар залларына Зәй шәһәренең мөмкинлекләре чикләнгән кешеләре ел дәвамында бушлай йөри.

Командалар Татарстан Республикасы инвалидларының физкультура-спорт җәмгыяте һәм спортның адаптив төрләре республика инклюзив фестивалендә үткәрелә торган спорт ярышларында катнашалар. Муниципаль берәмлектә үстерелә торган спорт төрләре булып өстәл теннисы, шахмат, шашка, кул көрәше, йөзү тора. Ярышларга йөртү җирле бюджет акчалары хисабына башкарыла.

Зәй муниципаль районының физик культура, спорт һәм туризм идарәсе район инвалидлар җәмгыяте белән берлектә ел саен йөзү, шашка, шахмат, дартс, өстәл теннисы буенча мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр арасында ярышлар үткәрә.

Өлкән яшьтәге кешеләр «Татарстан чаңгы юлы», «Татарстан кроссы» спорт акцияләрендә, Физкультурачы көнендә, «Раштуа чаңгы ярышы» традицион кышкы ярышларда, волейбол, футбол, баскетбол, шахмат һәм шашка ярышларында актив катнашалар. «Пульс» һәм «Өмет» өлкәннәр клубы әгъзалары активлык күрсәтә. Өлкән буын арасында йөзү, чаңгы, шахмат, җиңел атлетика ярышлары аеруча популяр.

«Энергия» стадионы базасында шахмат клубы эшли, анда 20гә якын кеше йөри. «Энергетик» мәдәният сараеның спорт залында атнага 2 тапкыр «Өмет» өлкәннәр клубы дәресләре уза, анда 50ләп кеше йөри.

Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының физик культура, спорт һәм туризм идарәсе ел саен пенсионерлар арасында шахмат һәм шашка буенча темпо-турнир һәм “Өченче буын” пенсионерлар Спартакиадасының муниципаль этапларын үткәрә, көчлеләр республика ярышларына сайлап алына.

Спорт инфраструктурасын үстерү һәм эзлекле камилләштерү өлкәсендә уңай динамика күзәтелә. 2020 ел ахырына Зәй муниципаль районында 195 спорт корылмасы эшләде.

Зәй муниципаль районында булдырылган спорт инфраструктурасы төрле яшьтәге меңләгән гражданга физик культура һәм спорт белән актив шөгыльләнергә мөмкинлек бирә.

Биш ел эчендә районның спорт объектларын ремонтлау һәм реконструкцияләүгә шактый финанс чаралары кертелде: 2014 елда Сәламәтлек мәктәбенә 26 229 873, 61 сумлык ремонт ясалды; 2016 елда «Ялта-Зәй» спорт комплексында чаңгы-роллер трассасы төзелешенә 88 млн. сум акча сарыф ителде; 2014 елда башланган «Энергия» стадионын

реконструкцияләүгә 2017 елда 73308,6 мең сум акча кертеп, ул эш төгәлләнде, шулай ук 2017 елда Олимпия чемпионы Федор Петрович Симашев исемендәге спорт мәктәбе бинасына 37, 7 млн. сумлык капиталь ремонт ясалды; 2017 елда «Энергетик» мәдәният сараена капиталь ремонт кысаларында спорт залы ремонтланды, хәзер анда өстәл теннисы белән шөгыльләнү өчен зал эшли.

Татарстан Республикасы Президенты һәм «Единая Россия» Бөтенроссия сәяси партиясе ярдәме белән универсаль мәйданчыклар төзү республика программасын гамәлгә ашыру кысаларында 2020 елда Зәй муниципаль районында Кадеров, Поручик һәм Якты Күл авылларында 9 135,66 мең сумлык 3 универсаль спорт мәйданчыгы төзелде. Спорт мәйданчыклары баскетбол һәм волейбол уйнау өчен каралган.

2020 елда шәһәрнең иң эре спорт объектларының берсе - 4388,3 квадрат метр мәйданлы спорт-сәламәтләндерү комплексына капиталь ремонтның 1 этабы башкарылды, аның составына универсаль спорт залы һәм 4 юллы йөзү бассейны керә. 2019 елның 11 декабрендәге 3204-р номерлы Министрлар Кабинеты боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан 39 987,6 мең сум күләмендә финанс чаралары бүлеп бирелде.

Шулай ук футбол буенча ел әйләнәсе сыйфатлы тренировкалар уздыру өчен мини-футбол кыры белән ябык футбол манежы төзү дә кирәк.

Районда физкультура-спорт юнәлешендәге 4 учреждение эшли, аларның 3се - спорт мәктәбе (алга таба - СМ), 1се - олимпия резервы спорт мәктәбе (алга таба-ОРСМ). Аларда 2403 кеше шөгыльләнә, 19 спорт төре буенча дәресләр алып барыла.

Муниципаль программада 2020-2022 елларга Зәй муниципаль районында физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыруның төп юнәлешләре чагылдырыла.

Муниципаль программа сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга, сәламәтлекне ныгытуга, халыкның барлык яшь төркемнәренең физик активлыгын һәм әзерлеген арттыруга, тулы канлы ял һәм сәламәт ял өчен шартлар тудыруга, спорт резервын әзерләүгә һәм Зәй муниципаль районы спортчыларының республика, Россия һәм халыкара спорт ярышларында уңышлы чыгыш ясауларына юнәлтелгән чараларны башкаруны күздә тота.

Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 03. 02.
53 номерлы карарына
4нче кушымта

Таблица 1

**"2020-2020 елларга Зәй муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау**

| Төп чараларның исемнәре | Башкаручылар | Чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның күрсәткече, елларга бүлеп | | | | Финанслау, мең сумнарда | | | Финанслау чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | База елы | 2020 | 2021 | 2022 | 2020 | 2021 | 2022 | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Массакүләм спортны үстерү | | | | | | | | | | | |
| Төрле категория халыкны физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп итү | УФКСиТ СШ СШОР | ел саен | Халыкның гомуми саныннан чыгып, физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче гражданнарның өлешен арттыру, (%) | 48,8 | 50,1 | 52,5 | 53,7 | - | - | - | - |
| | | | 3-6 | 95 | 95 | 95 | 96 | | | | |
| | | | 7-18 | 95 | 95 | 95 | 96 | | | | |
| | | | 19-29 | 41 | 42 | 43 | 44 | | | | |
| | | | 30-45 | 41 | 42 | 43 | 44 | | | | |
| | | | 46-60 | 41 | 42 | 43 | 44 | | | | |
| | | | 61-69 | 39 | 40 | 41 | 42 | | | | |
| | | | 70 һәм аннан өлкәнрәк | 21 | 22 | 23 | 24 | | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Барлык яшь категорияләре арасында спорт төрләре буенча чемпионатлар, беренчелекләр, кубоклар турнирлары һәм массакүләм ярышлар үткәрү | УФКСиТ СШ СШОР | ел саен | Үткәрелгән чаралар саны | 93 | 104 | 112 | 120 | 440,0 | 100,0 | 100,0 | Җирле бюджет |
| | | | Катнашучылар саны | 5580 | 6000 | 6480 | 6900 | | | | |
| Барлык яшь категорияләре арасында массакүләм спорт чаралары үткәрү | УФКСиТ СШ СШОР | ел саен | Үткәрелгән чаралар саны | 5 | 5 | 5 | 5 | 740,0 | 400,0 | 400,0 | Җирле бюджет |
| | | | Катнашучылар саны | 7200 | 7400 | 7600 | 7800 | | | | |
| Предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр командалары арасында «Сәламәтлек» спартакиадасы үткәрү | УФКСиТ СШ СШОР | ел саен | Үткәрелгән чаралар саны | 22 | 22 | 22 | 22 | 232,0 | 232,0 | 232,0 | Җирле бюджет |
| | | | Катнашучылар саны | 869 | 940 | 1010 | 1060 | | | | |
| Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән гражданнар һәм өлкән буын гражданнары арасында спорт ярышлары, спартакиадалар, фестивальләр, спорт бәйрәмнәре үткәрү, республика ярышларында катнашу | УФКСиТ СШ СШОР | ел саен | Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр арасында үткәрелгән чаралар саны | 4 | 8 | 12 | 16 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Җирле бюджет |
| | | | Өлкән буын арасында үткәрелгән чаралар саны | 4 | 11 | 15 | 19 | | | | |
| | | | Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән катнашучылар саны | 40 | 80 | 120 | 160 | | | | |
| | | | Өлкән буын арасында үткәрелгән чаралар саны | 45 | 220 | 300 | 380 | | | | |
| **Барысы** | | | | | | | | **1462,0** | **782,0** | **782,0** | |
| **«Хезмәткә һәм оборонага әзер!» Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы кысаларында эш оештыру** | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Хезмәткә һәм оборонага әзер!» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын барлык яшь категорияләре арасында сынап карау | УФКСиТ СШ СШОР | ел саен | ГТО нормаларын тапшырырга теркәлүчеләр өлеше, халыкның гомуми санына карата (%) | 18,79 | 24 | 25 | 26 | - | - | - | - |
| | | | ГТО комплексы сынаулары (тестлары) нормативларын үтәүдә катнашучылар өлеше, халык санына карата (%) | 13,35 | 18 | 19 | 20 | | | | |
| | | | Сынау нормативларын билгеләргә үтәүчеләр өлеше сынауларга керешүчеләр санына карата (%) | 27 | 28 | 29 | 30 | | | | |
| | | | Халык санына карата сынау нормативларын билгеләргә үтәүчеләр өлеше (%) | 7,52 | 8 | 8,5 | 9 | | | | |
| **Матди-техник базаны үстерү һәм ныгыту** | | | | | | | | | | | |
| Спорт-савыктыру комплексына капиталь ремонт | УФКСиТ СШ «Зай» | 2020-2021 | | | | | | 39 963,6 | ТР МК күрс. буенча | - | Республика бюджеты |
| Универсаль спорт мәйданчыклары төзү | УФКСиТ | ел саен | | | | | | ТР МК күрс. буенча | - | ТР МК күрс. буенча | Республика бюджеты |
| Мини-футбол кыры булган ябык футбол манежы төзү | УФКСиТ | 2021 | | | | | | - | ТР МК күрс. буенча | - | Республика бюджеты |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Барысы** | | | | | | | | **39 963,6** | **-** | **-** | |
| **Югары казанышлар спортын үстерү. Спорт резервын әзерләүнең нәтиҗәле системасын булдыру** | | | | | | | | | | | |
| Спорт мәктәпләрен тоту | СШ СШОР | ел саен | - | - | - | - | - | 93913,9 | 85 057,7 | 79 671,4 | Җирле бюджет |
| Спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларын җиһазландыру өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алу | УФКСиТ СШ СШОР | ел саен | - | - | - | - | - | 757,2 | ТР МК курс. буенча | ТР МК курс. буенча | Республика бюджеты |
| Спорт инвентаре, экипировка һәм җиһазлар сатып алу | | | | | | | | 500,0 | - | - | Республика бюджеты |
| ТР Зәй муниципаль районының «Яшьлек» спорт мәктәбе» МБУдә хоккейны үстерү | СШ «Яшьлек» | ел саен | - | - | - | - | - | 348,1 | ТР МК курс. буенча | ТР МК курс. буенча | Республика бюджеты |
| Аутсорсинг (спортчыларны ярышларга йөртү хезмәтләре) | СШ СШОР | | | | | | | 321,55 | - | - | Республика бюджеты |
| | | | | | | | | 14,47 | - | - | Җирле бюджет |
| Югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренеларга, шулай ук муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче спортчы - инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен түләү | УФКСиТ СШ СШОР | ел саен | - | - | - | - | - | ТР МК курс. буенча | ТР МК курс. буенча | ТР МК курс. буенча | Республика бюджеты |
| Физкультура-спорт оешмаларының яшь | УФКСиТ СШ | ел саен | - | - | - | - | - | ТР МК | ТР МК | ТР МК курс. | Республика |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| белгечләре-хезмәткәрләренә кызыксындыру өчен айлык өстәмә түләү | СШОР | | | | | | | күрс. буенча | күрс. буенча | буенча | бюджеты |
| Югары спорт осталыгына әзерләү һәм спорт осталыгын камилләштерү этапларында медицина контролен һәм спортчыларны тикшерүне тәэмин итү | СШ СШОР | ел саен | кеше | | 50 | 50 | 50 | - | 50,0 | 50,0 | Җирле бюджет |
| Календарь план нигезендә спорт мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрнең рәсми ярышларда катнашуын тәэмин итү | УФКСиТ СШ | ел саен | | | | | | 1 050,0 | 1 000,0 | 1 000,0 | Җирле бюджет |
| Календарь план нигезендә ир-атлар һәм хатын-кызлар җыелма командаларының рәсми ярышларда катнашуын тәэмин итү | УФКСиТ | | | | | | | 810,63 | 825,1 | 825,1 | Җирле бюджет |
| Спортчыларның физик әзерлеге һәм спорт осталыгы дәрәҗәсен күтәрү | СШ СШОР | ел саен | Разрядлы спортчылар саны, кеше: | | | | | - | - | - | - |
| | | | МС | 1 | 2 | 2 | 2 | - | - | - | |
| | | | КМС | 11 | 12 | 14 | 15 | - | - | - | |
| | | | 1 разряд | 20 | 22 | 24 | 26 | - | - | - | |
| | | | Ярышларда призерлар саны, кеше: | | | | | - | - | - | |
| | | | ТР беренчелеге | 60 | 65 | 70 | 75 | - | - | - | |
| | | | РФ беренчелеге | 7 | 8 | 9 | 10 | - | - | - | |
| | | | ТР чемпионаты | 10 | 12 | 14 | 15 | - | - | - | |
| | | | РФ чемпионаты | 3 | 3 | 3 | 3 | - | - | - | |
| | | | Җыелма командалар әгъзалары саны: | | | | | - | - | - | |
| | | | ТР | 31 | 32 | 33 | 34 | - | - | - | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | РФ | 9 | 10 | 10 | 10 | - | - | - | |
| **Барысы** | | | | | | | | **96894,3** | **86932,9** | **81 546,5** | |
| **Авыл җирлегендә физкультура-спорт эшен оештыру** | | | | | | | | | | | |
| Авыл җирлекләре командалары арасында «Сәламәтлек " спартакиадасы үткәрү | УФКСиТ СШ СШОР | ел саен | Үткәрелә торган ярышлар саны | 24 | 24 | 24 | 24 | 342,9 | 342,9 | 342,9 | Җирле бюджет |
| | | | Катнашучылар санын арттыру, кеше | 848 | 1015 | 1060 | 1110 | | | | |
| Район җыелма командаларының Татарстан Республикасы «Сәламәтлек» спартакиадасында катнашуын тәэмин итү | УФКСиТ | ел саен | - | - | - | - | - | - | - | - | Җирле бюджет |
| Район җыелма командасының «Авыл яшьләре " җәйге авыл уеннары финалында катнашуын тәэмин итү | УФКСиТ | 2 елга бер мәртәбә | - | - | - | - | - | - | - | - | Җирле бюджет |
| **Барысы** | | | | | | | | **342,9** | **342,9** | **342,9** | |
| **Физик культура һәм спорт өлкәсен кадрлар белән тәэмин итүне яхшырту** | | | | | | | | | | | |
| Физик культура һәм спорт өлкәсендә белгечләрне әзерләүне һәм яңадан әзерләүне оештыру | УФКСиТ СШОР | ел саен | Тренерларның квалификациясен күтәрү | - | - | - | - | - | - | - | - |
| Массакүләм спорт эшен планлаштыру тәҗрибәсен уртаклашу һәм гомумиләштерү буенча семинарлар, ачык дәресләр, киңәшмәләр үткәрү | УФКСиТ | ел саен | | - | - | - | - | - | - | - | - |
| Югары спорт нәтиҗәләренә ирешкән спортчылар арасыннан өлкән сыйныф укучылары белән һөнәри юнәлеш бирү эшен алып | УФКСиТ СШ СШОР | ел саен | | - | - | - | - | - | - | - | - |

